КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 27 май г.Казань № 491

Татарстан Республикасының төзелеш тармагында эшләүче беренче разрядлы эшченең уртача айлык хезмәте өчен түләү күләме турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелеш ресурслары бәяләрен мониторинглау турында» 2016 елның 23 декабрендәге 1452 номерлы карары белән расланган Төзелеш ресурслары бәяләрен мониторинглау кагыйдәләренең 22[1] нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу эшләренең, капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең, капиталь ремонтлауның, җимерүнең смета кыйммәтен билгеләү максатларында төзелеш тармагында эшләүче беренче разрядлы эшченең уртача айлык хезмәте өчен түләү күләмен 2021 елга 28 751,9 сумга тигез итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы төзелеш тармагында мәшгуль булган беренче разрядлы эшче хезмәте өчен түләүнең уртача айлык күләме турында» 2021 ел, 15 апрель, 250 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин